ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

18.09.2026 № 656

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләр ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру вәкаләтле органы һәм тәртибе турында» 2014 елның 31 мартындагы 351 номерлы карарын гамәлгә ашыру хакында» 2014 елның 14 апрелендәге 663 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты структурасында оештыру-штат үзгәрешләренә, сатып алулар бүлеген төзүгә бәйле рәвештә һәм районның норматив хокукый актларын җирле үзидарә органнарының факттагы структурасына туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләр ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру вәкаләтле органы һәм тәртибе турында» 2014 елның 31 мартындагы 351 номерлы карарын гамәлгә ашыру хакында» 2014 елның 14 апрелендәге 663 номерлы карарына (2024 елның 28 июнендәге № 587 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлеген дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле итеп билгеләргә.»

1.2. Муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр

сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турындагы нигезләмәдә (663 номерлы карарга 2 нче кушымта):

1.2.1. 1 бүлекнең 1.2.3 пунктчасында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының сатып алулар бүлеге» МБУ» сүзләрен «Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче

ЕМСЭД
**Республики Татарстан**
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 008D6B607BD8BB11EE7541AD211DD221A7
Владелец: Хакимуллин Рамиль Фатихович
Действителен с 15-01-2026 до 10-04-2027

Р.Ф. Хәкимуллин